Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«09» апрель 2024 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 9 апрелендә узган: «Сез элек расланган гражданнар җыенында чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Урта Чаллы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 10 октябрендәге 3 номерлы карары,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Урта Чаллы авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 10.10.2023 ел, № 4 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Сез 2024 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 131 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 68 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 66 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 2 катнашучысы тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Элек расланган гражданнар җыенында чыгарылган сорауга үзгәрешләр кертүгә сез риза булырсызмы?» дигән сорау буенча кабул ителгән карарны таныргa:

- «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Урта Чаллы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 10 октябрендәге 3 номерлы карары,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең Урта Чаллы авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 10.10.2023 ел, № 4 карары,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Сез 2024 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Чаллы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Н. Захаров

Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров